РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Совет

Базарно-Матакского сельского поселения Алькеевского

муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы

Базарлы Матак авыл җирлеге

Советы

422870, РТ, Алькеевский район,с. Базарные Матаки, Крайнова, 94

тел: 8 (84346) 21-5-62

Адресы: 422870, РТ, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Крайнов ур., 94

факс: 8 (84346) 21-5-62

**Решение** **Карар**

2021 елның 30 июле 39№

Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 66 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституция Судының 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы карары, 2019 елның 18 июлендәге «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 кисәгенең 16 пунктын үз көчен югалтуын тану, 2017 елның 29 гыйнварындагы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 463-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы 66 номерлы карарына (2018.24.08, 20№ редак.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 пунктның 44 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«янәшәдәге территория - җир кишәрлеге оештырылган һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән, бина, корылма, җир кишәрлеге янындагы гомуми файдалану территориясе;»

- 99 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«99. Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, иҗтимагый һәм җитештерү бинаалары, төзелеш һәм корылмалар һәм физик тәрбия-спорт, мәдәният оешмалары һәм башка оешмаларны да кертеп), ял итү урыннары янында I, II төркем инвалидлар белән идарә ителә торган транспорт чаралары һәм мондый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чаралары өчен бушлай парковка өчен урыннарның кимендә 10 процент (ләкин бер урынннан кимрәк түгел) бүлеп бирелә. III төркем инвалидлар арасыннан булган гражданнарга Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нормалары кагыла. Күрсәтелгән транспорт чараларында "Инвалид" таныклык билгесе куелырга һәм әлеге транспорт чаралары турында мәгълүмат федераль инвалидлар реестрына кертелергә тиеш.»

- 135.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләр бозылган, шул исәптән җир кишәрлеге оештырылмаган һәм дәүләт кадастр исәбенә куелмаган очракта, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
ТР Әлки муниципаль районы
Базарлы Матак авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Никошин